| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.10.2022 Баулы шәһәре № 73

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны, муниципаль хезмәт вазифаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган үзләренең һәм гаиләләре әгъзаларенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен тормышка ашыру максаты белән, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Указының 8 пункты нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтадагы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны, муниципаль хезмәт вазифаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган үзләренең һәм гаиләләре әгъзаларенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 27 февралендәге 128 номерлы карары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар, муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибен раслау хакында» 2021 елның 26 маендагы 32 номерлы карары (Баулы шәһәр Советының 2021 елның 14 декабрендәге 47 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының Законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Баулы шәһәре мэры,<br>
шәһәр Советы Рәисе — И.И. Гозәеров

Баулы шәһәр Советының
2022 елның ______ ____
номерлы карарына
кушымта

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны, муниципаль хезмәт вазифаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган үзләренең һәм гаиләләре әгъзаләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә түбәндәге вазифаларны биләүче затларга кагыла:

муниципаль вазифа (җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләүче башка зат);

Контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасы.

2. Әлеге Тәртип «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында (алга таба - сайт) әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән вазифаи затларның (алга таба - вазифаи затлар) , аларның ирләре һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру процедурасын, шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе билгеләнмәгән булса, массакүләм мәгълүмат чараларына аларны гарызнамәләренә бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү тәртибен регламентлаштыра.

3. Сайтта, бастырып чыгару өчен, түбәндәге белешмәләр урнаштырыла:

а) вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелгән исемлеге;

б) вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы транспорт чаралары төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләрен) санлы финанс активларын, цифрлы валюта сатып алу турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазифасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елдагы кеременнән артып китсә, һәм алыш-бирешкә тотылган акча чыганаклары турында.».

4. Сайтта урнаштырыла торган белешмәләрдә түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрдән тыш, вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, күрсәтелгән затларга милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка белешмәләрне;

б) ир яисә хатынның (иренең) яисә хатынының, балаларның һәм вазифаи зат гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси мәгълүматын;

в) вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм аралашуның башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны;

г) вазифаи затка, аның хатынына (иренә), балаларына, гаиләнең башка әгъзаларына караган яисә алар файдалануындагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматны;

д) конфиденциаль булган мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр аларны бирү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң сайтта 14 эш көне эчендә урнаштырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру Баулы муниципаль Советы Аппаратын кадрлар белән тәэмин итү бүлеге тарафыннан тәэмин ителә.

7. Сайтта урнаштырылган белешмәләр, шул исәптән алдагы елларда, ачык кулланылышта һәм юкка чыгарылырга тиеш түгел.

8. Вазифаи зат төгәлләштерелгән белешмәләр тапшырганда, тиешле үзгәрешләр төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

9. Баулы муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен җавап тота.

10. Баулы муниципаль районы Советы Аппаратын кадрлар белән тәэмин итү бүлегенең муниципаль хезмәткәрләре конфиденциаль булган мәгълүматларны тарату өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.